ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь 2022 ел № 5772

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру максатында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары белән расланган «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 270 756,11 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 423 585,37 мең сум, 2024 ел – 423 585,37 мең сум, 2025 ел – 423 585,37 мең сум.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 25 октябрендәге
5772 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы;<br>4. Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы |
| Программаны эшләүче | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | - Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе<br>- Башкарма комитетның мәгариф идарәсе<br>- Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе (килешү буенча)<br>- Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе<br>- Башкарма комитетның финанс идарәсе |
| Программаның максатлары | 1) юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын 9 кешегә кадәр киметү;<br>2) Җәмәгать пассажир транспорты катнашында юл-транспорт һәлакәтеен 25 кә кадәр киметү;<br>1) 3) Урам-юл челтәренең (алга таба – УЮЧ) норматив техник торышын ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту. |
| Программаның бурычлары | 1) Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;<br>2) Машина йөртү культурасын арттыру;<br>3) юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү. |

| | |
|---|---|
| | 4) Урам-юл челтәренең норматив техник торышын саклап тоту |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | Программа 2023, 2024, 2025 елларга исәпләнгән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | |
| | | 2023 | 2024 | 2025 |
| | Муниципаль бюджет | 423 585,37 мең сум | 423 585,37 мең сум | 423 585,37 мең сум |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Узган елның аналогик чоры белән чагыштырганда, 2023-2025 еллар азагына юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санын 25% ка, зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре санын 10% ка киметү |
| Программаны тормышка ашыруга контроль | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |

2 бүлек. Хәл итү өчен муниципаль программа юнәлдерелгән проблемаларны күрсәтеп, аңлатма язуы

2022 елның 6 аенда Яр Чаллы шәһәре территориясендә зыян күрүчеләр белән 208 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 5 кеше һәлак булган һәм 278 кеше төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Узган елның аналогик чоры (алга таба – УЕАЧ) белән чагыштырганда һәлакәтләр саны 11,1% ка (УЕАЧ 234; -26 юл-транспорт һәлакәте) һәм җәрәхәтләнүчеләр 0,7% ка (УЕАЧ 280; -2 кеше) кимегән.

Шәһәрдә «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» (КСЮ) милли проектында каралган исәп-хисап максатчан күрсәткече үтәлгән, фаразланган күрсәткеч 5 булганда, 5 кеше һәлак булган.

2022 елның 6 аенда хезмәт күрсәтелә торган территориядә 77 җәяүлене бәрдерү очрагы теркәлгән (УЕАЧ 91), анда 3 кеше һәлак булган (УЕАЧ 1) һәм 77 җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 93). Әлеге юл-транспорт һәлакәтендә һәлак булучылар саны 2 кешегә арткан, шулардан ике юл-транспорт һәлакәте машина йөртүчеләр гаебе, 1 юл-транспорт һәлакәте исерек хәлдәге җәяүленең үз гаебе белән булган.

Балаларның юл-транспорт травматизмы

2022 елның 6 аенда Яр Чаллы шәһәре юлларында 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 57 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 1 бала һәлак булган һәм балигъ булмаган 64 бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Узган елның аналогик чорында 57 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 1 бала һәлак булган һәм балигъ булмаган 60 бала зыян күргән. Юл-транспорт һәлакәтләре саны узган ел дәрәҗәсендә калган, зыян күрүчеләр саны 6,7% ка арткан.

Юл-транспорт һәлакәтендә зыян күргән балалар категориясе буенча караганда, балалар еш кына җәяүлеләр сыйфатында – 35 бәрдерүгә (УЕАЧ 30), пассажирлар сыйфатында 17 юл-транспорт һәлакәтенә (УЕАЧ 18), велосипедчы сыйфатында 5 юл-транспорт һәлакәтенә (УЕАЧ 9) юлыккан.

Җәяүлеләр кичүендә 21 тапкыр бәрдерү (УЕАЧ 9) очрагы булган, аларда 1 бала һәлак булган (УЕАЧ 0) һәм балигъ булмаган 21 җәяүле җәрәхәтләр алган (УЕАЧ 10):

- җайга салынмый торган – 17 тапкыр бәрдерү (УЕАЧ 6);
- җайга салына торган – 4 тапкыр бәрдерү (УЕАЧ 3).

Балигъ булмаганнар гаебе белән юл-транспорт һәлакәтләре санының сизелерлек кимүе күзәтелә. Балигъ булмаганнар гаебе белән 14 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 24 проценты (УЕАЧ 28 яки 49%), шуларның 11 балигъ булмаган җәяүлеләр гаебе белән, 3 юл-транспорт һәлакәте велосипедчысы гаебе белән. Җәяүлеләр арасында балигъ булмаганнарның саксызлыгы аркасында юл-транспорт һәлакәтләренең киң таралган төре булып машина йөртүченең күрүен чикләүче каршылыклар артыннан машина юлына чыгуы; велосипедчылар арасында – 14 яшькә җитмәгән велосипедчының машаина юлында хәрәкәт итүе тора.

Шулай ук балигъ булмаган пассажирлар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны киму күзәтелә. Узган чорда балигъ булмаган пассажирлар катнашында 17 юл-транспорт һәлакәте (УЕАЧ 18) теркәлгән, аларда 24 балигъ булмаган пассажир җәрәхәтләр алган (УЕАЧ 20). Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып йөрткән юл-транспорт һәлакәтләре теркәлмәгән (УЕАЧ 2).

## 3 бүлек. Программа чаралары.
## Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау.

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чаораларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганаклары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2022 база | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| Юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын киметү | Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы ясау системасы булдыру | «Яшь Хәрәкәт Инспекторы» кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары белән «Куркынычсыз тәгәрмәч» конкурсы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Ел саен | Катнашкан укучылар саны, кеше | 270 | 280 | 280 | 280 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен «Игътибар - балалар!», «Игътибар - җәяүле!», акцияләре | | Ел саен | Гомуми белем бирү учреждениеләре нең гомуми санында катнашкан укучылар өлеше, % | 95 | 95 | 95 | 95 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны куркынычсыз юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү буенча «Куркынычсыз | | Ел саен, уку елы дәвамында | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Чара оештыру характерына ия | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | юл» дидактик уеннар зональ конкурсы | | | | | | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Юл хәрәкәте иминлеге» темасына лекцияләр | Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | Ел саен, уку елы дәвамында | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 65 | 65 | 65 | 65 | Чара оештыру характерына ия |
| | | Массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте имин леген тәэмин итү буенча материалларны яктырту | Мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Даими | Урнаштырылган материаллар саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | Чара оештыру характерына ия |
| Җәмәгать пассажирлар транспорты катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен кимету | Машина йөртү культурасын арттыру | «Хаким Кубогы»на магистраль автопоездлар йөртүчеләрнең һөнәри осталык бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Татарстанның Логистика ассоциациясе (килешү буенча) | Ел саен | Катнашучылар саны, кеше | 30 | 30 | 30 | 30 | Чара оештыру характерына ия |
| | | Җәмәгать транспортын йөртүчеләрнең һөнәри осталык шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, «Пассажирлар йөртү» ҖЧҖ | Ел саен | Катнашучылар саны, кеше | 25 | 25 | 25 | 25 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Җәмәгать транспорты йөртүчеләр белән стресс тотрыклылыгы һәм клиент ориентлашуы буенча курслар | (килешү буенча) | Ел саен | Үткәрелгән лекцияләр саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | Чара оештыру характерына ия | | |
| УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту | УЮЧнең норматив техник халәтен саклап тоту | Юллар, күперләр һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Ел саен | Карап тотуны боззу буенча ЮХИДИ күрсәтмәләренең саны | 200 | 195 | 190 | 185 | 423 585, 37 мең сум | 423 585 ,37 мең сум | 423 585, 37 мең сум |
| | | Юлларны кыш көне карап тоту | | Ел саен | Карап тотуны боззу буенча ЮХИДИ күрсәтмәләренең саны | 29 | 29 | 28 | 27 | | | |
| | | Юл билгеләре урнаштыру | | Ел саен | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнаштырылган юл билгеләренең өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | Юл билгеләре төшерү | | Ел саен | Юл билгесе булган автомобиль юлларының өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | Светофор объектлары | | Ел саен | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнаштырылган светофор объектларының өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү (муниципаль программага кушымта) | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Ел саен | Бетерелә торган юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарының саны | 13 | 13 | 12 | 11 | |

## 4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 270 756,11 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2023 ел – 423 585,37 мең сум, 2024 ел – 423 585,37 мең сум, 2025 ел – 423 585,37 мең сум.

## 5 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе үз компетенциясе чикләрендә программа чараларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешелә:

1) юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын киметү;

2) җәмәгать пассажир транспорты катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен киметү;

3) урам-юл челтәренең норматив техник торышын саклау.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасына
кушымта

Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү

| № т/б | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе адресы | Аварияләрне киметү буенча тәкъдим ителә торган чаралар | Финанслау чыганагы/программа |
|---|---|---|---|
| 1. | Тынычлык проспекты – Яшьлек проспекты | Тынычлык проспекты һәм А. Алиш урамы буенча:<br>- тавыш полосалары урнаштыру;<br>Яшьлек проспекты буенча:<br>- тавыш полосалары урнаштыру;<br>- аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюҗет |
| 2. | Сөембикә проспекты – Халыклар Дуслыгы проспекты | - юл чатын реконструкцияләү (юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү) | «Урам-юл челтәрен ремонтлау» республика программасы кысаларында |
| 3. | Машиностроительная урамы, 76 (Вахитов боҗрасы) | - 1.1 һәм 1.18 горизонталь билге линияләре (юл чатында полосалар буенча рөхсәт ителгән хәрәкәт юнәлешен күрсәтә торган) урнаштыру | Җирле бюҗет |
| 4. | Вахитов проспекты – Ш. Усманов урамы | Вахитов проспекты буенча:<br>- җәяүлеләр кичүендә яктылыкны арттыру | Җирле бюҗет |
| 5. | Шамил Усманов урамы, 36 «А» | - 2 ясалма тигезсезлекне төзекләндерү | |
| 6. | В. Гостев урамы – В. Фоменко проспекты | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру;<br>- светофорның эш режимын үзгәртү | Җирле бюҗет |
| 7. | Яр Чаллы проспекты - Désinститут | Яр Чаллы проспекты буенча:<br>- тавыш полосалары урнаштыру | Җирле бюҗет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Чулман проспекты – Автозавод проспекты | - җәяүлеләр кичүендә яктылыкны арттыру;<br>- светофорның эш режимын үзгәртү | Җирле бюджет |
| 9. | Залесный проспекты, 45 | - тавыш полосалары урнаштыру;<br>- «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләре урнаштыру;<br>- щитта утны кире кайтаручы саргылт-яшел төстәге флуоресцент пленкалы «Максималь тизлекне чикләү» 3.24 юл билгесе (40 км/сәг) урнаштыру | Җирле бюджет |
| 10. | Машиностроительная урамы, 12 «В» («Беркут» базасы) | - чакыру җайланмалы светофор объекты төзү | Җирле бюджет |
| 11. | Тынычлык проспекты – Автозавод проспекты | - тавыш полосалары урнаштыру | Җирле бюджет |
| 12. | Тынычлык проспекты, 94 йорт | - хәрәкәтне туктату җайланмасы булган светофор объекты төзү | Җирле бюджет |
| 13. | Тынычлык проспект – Халыклар Дуслыгы проспекты | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 14. | Х. Туфан проспекты – Сөембикә проспекты | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 15. | Тынычлык проспекты – Рәис Беляев проспекты | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 16. | Г. Тукай яр буе– Батенчук Е.Н. урамы | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 17. | Яр Чаллы проспекты – Нариманов урамы | - аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 18. | М. Җәлил проспекты, 20 йорт | - бүлү полосасында җәяүлеләр киртәләре урнаштыру | Җирле бюджет |
| 19. | Трубный тыкрыгы, 23 йорт | - щитта утны кире кайтаручы саргылт-яшел төстәге флуоресцент пленкалы «Максималь тизлекне чикләү» 3.24 юл билгесе (40 км/сәг) урнаштыру | Җирле бюджет |
| 20. | Чулман проспекты – Х. Туфан проспекты | - тавыш полосалары урнаштыру;<br>- аксыл-ай төсендә җемелдәү режимлы мәгълүмати яктылык секцияләре урнаштыру | Җирле бюджет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21. | Промышленная урамы,<br>49 йорт, 3 төзелмә | - металл киртәләр урнаштыру | Җирле бюджет |
| 22. | Әлмәт тракты, 2 йорт | - тавыш полосалары урнаштыру | Җирле бюджет |
| 23. | Профильная урамы | - тиешле юл билгеләре белән ясалма тигезсезлек урнаштыру;<br>- Профильная урамы – Огнеборье урамы чатында<br>ясалма яктылык урнаштыру<br>Юл билгеләре урнаштыру<br>5.20 – 2 данә<br>1.17 - 2 данә<br>3.24 - 1 данә | Җирле бюджет |